**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге составына керүче Байлар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«26» ноябрь 2022 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2022 елның 26 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Байлар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Байлар торак пунктының Яңа тыкрыгындагы юлны норматив хәлгә китерү (төзү, реконтсрукцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак ком-таш катнашмасы җәю, төзелеш материаллары сатып алу, кайтару, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- зират коймасы урнаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдерлаштыру, юлларны кардан чистарту, эшләр өчен килешү нигезендә түләү)” соравы буенча.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 327 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә 166 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда 159 кеше тавыш бирде;
- «ЮК» позициясе өчен җыенда катнашкан 7 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пунктында халык җыенын узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «2023 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Байлар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Байлар торак пунктының Яңа тыкрыгындагы юлны норматив хәлгә китерү (төзү, реконтсрукцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак ком-таш катнашмасы җәю, төзелеш материаллары сатып алу, кайтару, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- зират коймасы урнаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдерлаштыру, юлларны кардан чистарту, эшләр өчен килешү нигезендә түләү)” буенча сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга мөмкин: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова